СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СУГУШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«СУГУШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 14 мартыннан №6

«Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Сугышлыавыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре шулай ук, әгәр бу бозып күрсәтелгән мәгълүматлар мөһим булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы ( 26.01.2023 ел ред.) Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Сугышлыавыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре шулай ук, әгәр бу бозып күрсәтелгән мәгълүматлар мөһим булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дерес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында, 4 пунктында, 5 пунктның 3 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1,3 абзацларында «Президентны» сүзен «Башлыгын - Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның 1 абзацында «Президентка» сүзен «Башлыгына - Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк ур., 27 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендын халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе
вазыйфаларын башкаручы И.З.Миназов